**СОВЕТ НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ**
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы, 423190

тел .: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

Бишенче чакырылыш Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы Советы
КАРАРЫ

2025 елның «20» ноябреннән № 3-15

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районында 2026 елны Балаларны һәм яшьләрне һәрьяклап үстерү елы дип игълан итү турында

Җәмгыять ресурсларын һәм муниципалитетны киләчәк буын потенциалын ныгытуга туплау, һәр баланың һәм яшьләрнең лаеклы үсешен тәэмин итү, күпмилләтлелек шартларында патриотик тәрбия бирү максатларында Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районында 2026 елны Балаларны һәм яшьләрне һәрьяклап үстерү елы дип игълан итәргә.
2. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетына:

бер ай вакыт эчендә Яңа Чишмә муниципаль районында Балаларны һәм яшьләрне һәрьяклап үстерү елын уздыру буенча оештыру комитеты төзергә һәм аның составын расларга;

ике айвакыт эчендә Яңа Чишмә районында Балаларны һәм яшьләрне һәрьяклап үстерү елын уздыру буенча төп чаралар планын эшләргә һәм расларга.

3. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының авыл җирлекләре башлыкларына Балаларны һәм яшьләрне һәрьяклап үстерү елы кысаларында авыл җирлекләре территориясендә чаралар үткәрүне оештырырга тәкъдим итәргә.
4. Яңа Чишмә муниципаль районы территориясендәге иҗтимагый берләшмәләргә һәм оешмаларга районда Балаларны һәм яшьләрне һәрьяклап үстерү елын әзерләүдә һәм уздыруда актив катнашуны тәкъдим итәргә.
5. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда: https//pravo.tatarstan.ru, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында: https//novosheshminsk.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.
6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының бюджет, салымнар һәм финанслар буенча даими депутат комиссиясенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә
муниципаль районаы Башлыгы Е.А. Тарнавский